ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘН ҺӘМ БЕЛЕМ МИНИСТРЛЫГЫ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
КИЧКЕТАҢ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ

*БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНДА ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН СОЧИНЕНИЕЛӘР КОНКУРСЫ*

*Номинация: «Истә, һаман да истә...»*

# *Минем гаиләм язмышында Бөек Ватан сугышы*

*Башкарды: 6 сыйныф укучысы*
*Муллануров Динар Илдар улы*
*Җитәкче: Татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәймөхәммәтова Әлфия Искәндәр кызы*

2014 ел

1941 елның ямьле 22 июнь иртәсе. Табигатьнең иң ямьле мәле. Урман - болыннарда кошлар сайрый, аланнар шау чәчәктә. Һәр чәчәктә эшчән бал кортлары чәчәктән-чәчәккә кунып бал җыя. Аллы-гөлле чәчәкле болыннарда кызарып җир җиләкләре пешеп утыра. Колхозда тыгыз печән өсте.

Кинәт боларның барысын да куркыныч, дәһшәтле хәбәр юкка чыгара. Явыз Гитлер сугыш башлаган. Немец гаскәрләре илебезгә бәреп кергән, шәһәр-авылларны яндырган, кан-яшь, гарасат…

Авылларда ир-егетләрне сугышка алу башлана. Сугыш башланганның икенче көнендә үк Кичкетаң авылыннан 23 ир-егеткә чакыру кәгазьләре килә. Шулар арасында минем Вагыйз бабамның әтисе Муллануров Габделхай бабай да була. Һәр көн 18 яше тулган ир-егетләрне сугышка алалар. Озак та үтми, бабамның абыйлары Салих белән Мөхәммәтне, әбиемнең әтисе Галимов Мулланур Латыйп улын да сугышка алалар. Шулай итеп, дәү әбием һәм дәү бабамнар гаиләсеннән дүрт кеше сугышка китә.

Дәү бабам Муллануров Габделхәй Мулланур улы 1908 елда элекке Красный Бор районы Кичкетан авылында туып үскән. Авылыбызның указлы мулласында белем ала. Гарәп телен һәм математиканы яратып өйрәнгән. Колхозлашу чоры башлангач, атларын, сыерларын биреп, колхозга кергәннәр. Белемен тирәнәйтү максатыннан, күрше Шаршады авылында белем ала. Шаршады мәктәбен тәмамлаганнан соң, Габделхәй бабам колхозда җаваплы һәм оештыру эшләрен башкара.

1931 елда авыл гүзәле Галимә белән тормыш коралар. Ун ел бәхетле тормышның нәтиҗәсе: тупырдап дүрт балалары үсеп килә.

1941 елның 23 июнь көне бәхетле гаиләгә кара кайгы китерә. Дәү бабам Габделхәй, дүрт нарасый баласын, тормыш иптәше Галимәне ялгыз калдырып, сугышка китә.

Авылда карт-коры, хатын-кыз, бала-чага гына кала. Тормышның барлык авырлыклары алар җилкәсенә төшә. Кул арбасы белән утын һәм печән хәзерләү, сыер-үгез җигеп җир сөрү, чәчүлек эшләре, урак белән ашлык уру... Тора-бара тормышлар тагын да авырлаша. Үзәкләргә үткән ачлык, ялангачлык, сугыш афәте, “печәтле кара кәгазь”, ятимлек ачысы...

“Истә, һаман да истә. Ул еллар онытылмыйлар”,-ди бабам, бала-чагын искә төшергәндә. Ирексездән аның күзләре яшьләнә.

Ни кызганыч, рәхимсез сугыш беркемне дә аямый. Галимә әбием 31 яшендә дүрт баласы белән тол кала. Габделхәй бабам шул китүеннән кире әйләнеп кайтмый. Галимә әбием кара таңнан кара төнгә чаклы колхоз эшендә, ә өйдә 4 бала: олысына 9 яшь, иң кечесенә 1 яшь тә 6 ай була. Балалар берсен-берсе карап, исән-сау үсәләр. Сугыш юк иткән әтиләрен алар гомер буе көтәләр.

Бабам белән әбием гаиләсеннән 4 кеше сугышка китә һәм дүртесе дә кире әйләнеп кайтмый. Илебезне дошманнардан саклаганда, батырларча һәлак булалар.

Кичкетаң авылыннан 239 кеше сугышка китә. Шуларның 101 кире туган якларына кайтса, 138 авылдашыбызга исән-имин кайту насыйп булмый. Чит җирләрдә ятып калган авылдашларымның исемнәре хәтер китабына кертелгән һәм мәңгелек ут каршындагы мәрмәр ташка уеп язылган.

Явыз дошман бик күп шәһәр-авылларны җир белән тигезләсә дә, күпме халкымны юк итсә дә, җиңү безнең якта була. Халыклар бердәмлеге җиңүгә китерә. Илебез халкы, туганнарыбыз, якыннарыбыз, якташларыбыз тир һәм кан коеп җиңү яулаган, безгә бәхетле тыныч тормыш, аяз күк йөзе бүләк иткән.

Күпме бәла-каза китергән, кеше гомерен өзгән бу дәһшәтле канкойгыч сугыш башкаларга да гыйбрәт булсын, сугышлар янә дә кабатланмасын иде. Украина бу сугышны кабатламаса иде.

Без, җиңүчеләр буыны төзеп биргән бүгенге иректе мул тормышта яшәүчеләр. Безнең бурыч: үлгәннәрнең каберен, ә исәннәрнең кадерен белергә, тиешле хөрмәтебезне күрсәтергә тиешбез. Үткәннәрне белмәгән халыкның киләчәге юк. Без тарихыбыз белән кызыксынырга, аны өйрәнергә бурычлы.

Халкыбызның Бөек Ватан сугышындагы тиңдәшсез батырлыгы безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.